# Аерымланган хәлләр янында тыныш билгеләре

***Үзләре бәйләнгән җөмлә кисәгеннән ераклашкан һәм ярым хәбәрлек төшенчәсенә ия булган хәлләр аерымлана. Аерымланган хәлләр җөмләнең төрле урыннарында (алдан, уртада, ахырдан) килергә мөмкин. Уртада килгәндә, алар ике яктан да өтер белән аерыла, калган очракта өтер бер ятка гына куела.***

***Авылга кайту белән***, *көтү Вәли бай ишегалдына куылды. Ә Әйдүкнең үзен өйгә алып керделәр.*

*-Әйт, кемнәр сыерларын алып китте?-дип акырды староста,* ***аның колагына борылып.***

*Әйдүк җавап бирмәде. Аны,* ***эт урынына кыйнап***, *урманга ыргыттылар.(Һ.Такташ)*

**Сания абыйсы артынннан тиз-тиз атлап бара**

**Балалар түгәрәк күл буена  су коенырга дип килделәр.**

**Кошлар киң тугайны яңгыратып сайрый**

**Алсу бакчаларына ял иткәч чыкты.**

**Сания абыйсы артынннан тиз-тиз атлап бара**.(Сания, тиз-тиз атлап, абыйсы артыннан бара)

**Балалар түгәрәк күл буена  су коенырга дип килделәр**. (Балалар, су коенырга дип, түгәрәк күл буена килделәр)

**Кошлар киң тугайны яңгыратып сайрый**.(Киң тугайны яңгыратып, кошлар сайрый)

**Алсу бакчаларына ял иткәч чыкты**. (Алсу, ял иткәч, бакчаларына чыкты.)

1.Нужадан йөрсәләр дә, күрәсең, бик үк ярлыдан булмаганнардыр.(Х.С)

2.Халык арасыннан, кулына чыбыркысын тотып, Нәфисәнең атасы килеп чыкты.(Г.Б)

3.Хөсәен, Ильясны озаткач, бераз уйлап утырды.

4.Эшләрнең барышы белән танышырга дип, Гөлзифа идарәгә юнәлде.(Р.Т)

5.Әгәр бик теләсәң, син моңа җавап табасың.

6.Авыру сәбәпле, Гөлназ бүген эшкә бара алмады.

# Дөрес җаваплар

| Хәл төре | 1җөмлә | 2җөмлә | 3 җөмлә | 4 җөмлә | 5җөмлә | 6 җөмлә |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| Вакыт хәле | | | + | | | |
| Сәбәп хәле | | | | | | + |
| Максат хәле | | | | + | | |
| Рәвеш хәле | | + | | | | |
| Шарт хәле | | | | | + | |
| Кире хәл | + | | | | | |